# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«03» 07 2026 ел　　　　　Яр Чаллы ш.　　　　　№ 56

16:39:080301:679 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 26 июнендәге 01-09-14921 номерлы хаты нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 16:39:080301:679 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле үзидарә турында, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә халык тыңлауларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
3. Халык тыңлауларын үткәрү 2026 елның 3 августыннан да соңга калмыйча тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы　　　　　　　　　　　　К.Р. Нәҗмиев